**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 гыйнварындагы 15 номерлы карары**

**«2025 – 2027 елларга Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. «2025 – 2027 елларга Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын (алга таба – Программа) кушымта нигезендә расларга.

2. Ел саен, 2025 елдан башлап, Казан шәһәре Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле чыгымнарны Программа кысаларында һәм, тиешле бюджет икътисади классификациясен кулланып, чираттагы финанс елына Казан шәһәренең бюджет исемлегендә исәпкә алына торган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсенә:

3.1. квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 числосына кадәр, Программага 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына Программаны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат юлларга;

3.2. ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны әзерләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат юлларга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 гыйнварындагы
15 номерлы карары белән
расланды

«2025 – 2027 елларга Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру»

# МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**Муниципаль программа**
**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2025 – 2027 елларга Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы |
| Муниципаль заказчы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны эшләүче | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты – шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдә булган закон таләпләренең һәм нормативларның Казан шәһәре территориясендә үтәлешен тәэмин итү.<br>Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү зарур:<br>1) капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү;<br>2) Казан шәһәре территориясендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү очракларын кисәтү буенча эш оештыру;<br>3) муниципаль программаны гамәлгә ашыруны оештыру ягыннан тәэмин итү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | Программа өч ел дәвамында гамәлгә ашырыла (2025 – 2027 еллар) |
| Ярдәмче программалар исемлеге | Юк |
| Еллар һәм чыганаклар буенча | Программаны финанслауның гомуми күләме 92 392,3 мең сумны тәшкил итә |

<table>
<tr>
<td>бүлеп,<br>Программаны финанслау күләме</td>
<td>
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="3">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Барлыгы</th><th>Казан шәһәре муниципаль бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклар</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>30 081,1</td><td>30 081,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>30 443,1</td><td>30 443,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>31 868,1</td><td>31 868,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>БАР-ЛЫГЫ</td><td>92 392,3</td><td>92 392,3</td><td>-</td></tr>
</table>
Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td>
<td>Билгеләнгән программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне башкарырга мөмкинлек бирәчәк:<br>- Казан шәһәре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру барышында объектларны төзүгә, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирүне (озайтуны) тәэмин итәргә;<br>- җирле әһәмияттәге һәйкәлләр реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздыруга рөхсәт бирүне, шулай ук җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү актын бирүне тәэмин итәргә;<br>- Казан шәһәре территориясендә ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр уздыруны раслый торган документ бирүне тәэмин итәргә;<br>- шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын төзүне яисә реконструкцияләүне планлаштырганда яки төгәлләгәндә хәбәрнамәләр бирүне тәэмин итәргә;<br>- рөхсәт бирүне кире кагу турында карар бирүне тәэмин итәргә</td>
</tr>
</table>

**I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, төп мәсьәләләр һәм аларны хәл итү юллары**

Шәһәр төзелеше түбәндәге төп төшенчәләрне үз эченә алган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән регламентлана:

- шәһәр төзелеше эшчәнлеге – территорияләрне, шул исәптән шәһәрләрне һәм башка торак пунктларны территориаль планлаштыру, шәһәр төзелеше буенча зоналарга бүлү, территорияне планлаштыру, архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру, төзү, капиталь ремонтлау, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, биналарны, корылмаларны эксплуатацияләү, территорияләрне төзекләндерү рәвешендә үстерү буенча эшчәнлек;

- территориаль планлаштыру – территорияләрне үстерүне, шул исәптән функциональ зоналар урнаштыру, федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны план буенча урнаштыруны билгеләү өчен планлаштыру;

- территорияләрне тотрыклы үстерү – шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында куркынычсызлыкны һәм кеше тормышы эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар булдыруны тәэмин итү, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең тирә-як мохиткә тискәре йогынтысын чикләү, хәзерге һәм киләчәк буыннар мәнфәгатьләреннән чыгып, табигать ресурсларын саклауны һәм алардан рациональ файдалануны тәэмин итү;

- шәһәр төзелеше буенча зоналаштыру – территориаль зоналарны билгеләү һәм шәһәр төзелеше регламентларын гамәлгә кертү максатыннан муниципаль берәмлекләр территорияләрен зоналарга бүлү;

- төзелеш – биналар, корылмалар төзү (шул исәптән сүтелә торган капиталь төзелеш объектлары урынында).

Хәзерге вакытта шәһәр төзелеше эшчәнлегенең роле һәм әһәмияте сизелерлек арта бара. Бу эшлекле, социаль һәм төзелеш активлыгы, инфраструктураны камилләштерү, шәһәрләрне төзү һәм реконструкцияләү, шәһәр мохитенең экологик торышын яхшырту кебек озак вакытка исәпләнгән юнәлешләрнең ресурслар белән тәэмин ителеше арту белән бәйле.

Барлык заказчылар, инвесторлар, төзүчеләр Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше законнары нигезендә шәһәр төзелеше һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруда тигез хокукларга ия. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр йогынтысына дучар булган территорияләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге аерым рәвештә җайга салынырга тиеш. Гадәттән тыш техноген хәлләрне булдырмый калу бурычы тиешле шәһәр төзелеше

нормаларын һәм кагыйдәләрен, объектларны имин эксплуатацияләү таләпләрен төгәл үтәү юлы белән хәл ителә. Кызганыч, хәзерге вакытта җир тетрәү, су басу, җир шуышу һәм башка табигать катаклизмнары кебек табигый көчләрнең тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә күчемсез милек объектлары төзүне чикли торган законнар юк диярлек.

Бүген әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтү системаларын оештыруның кайбер мәсьәләләре генә җайга салынган.

Төзелеш – кешеләр һәм әйләнә-тирә мохит өчен потенциаль куркыныч эшчәнлек төре, шуңа күрә шәһәр төзелеше законнары биналарның, корылмаларның, әйләнә-тирә мохитнең иминлеген тәэмин итүгә, хәвеф-хәтәрләрне кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар системасын билгели. Законнар белән билгеләнгән барлык процедуралар да үтәлеше мәҗбүри булган таләпләрне үз эченә ала.

Төзелә торган капиталь төзелеш объектларының куркынычсызлыгын тәэмин итү белән бәйле мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм аңа туры китереп эшләнгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив-хокукый актлары белән җайга салына. Кызганыч, объектларны рөхсәтсез төзү бүген дә дәвам итә. Рөхсәтсез төзелгән корылма закон регламентларын аңлы рәвештә игътибарга алмау нәтиҗәсе булып тора. Рөхсәтсез төзелгән корылмалар беренче чиратта муниципаль берәмлекләрнең гавами мәнфәгатьләрен бозганга күрә, әлеге күренеш белән көрәшүнең иң нәтиҗәле чарасы – рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турындагы дәгъва белән мөрәҗәгать итү. Рөхсәтсез төзелгән корылмалар мәсьәләсе шәхси торак төзелеше сыйфатында күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле рәвештә аеруча актуальләште.

Казан шәһәре Думасының 2012 елның 7 июнендәге 4-14 номерлы карары (соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзүчеләр билгеле бер таләпләрне үтәргә тиеш. Җир һәм төзелеш-монтажлау эшләрен башкарганда төзелеш мәйданнарында подрядчы оешмалар тарафыннан кагыйдә бозуларның иң еш очрый торган очраклары эшләр башкаруның вакытын бозу, туфракны, төзелеш материалларын дөрес сакламау, коймаларның гамәлдәге таләпләргә туры килмәве, урнаштырылган билгеләрнең булмавы белән бәйле. Автомобильләр юлының асфальт-бетон өслегеен торгызу, төзүче оешманың төзелеш мәйданчыгы коймасы периметры буенча 5 метрлы зонаны чистарту буенча бурычларны үтәмәве хәл ителмәгән мәсьәлә булып кала.

Әлеге программа шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсе нигезен тәшкил итүче федераль һәм республика норматив хокукый актларына таянып эшләнде һәм гамәлгә ашыру барышында Казан шәһәре Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе вәкаләтләре кысаларында Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдә булган законнар таләпләренең һәм нормативларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

«2019 – 2024 елларга Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының төп чараларын башкару нәтиҗәсендә 2019 – 2023 елларда соңгы нәтиҗәләрне бәяләү күрсәткечләре 100 процентны тәшкил итте.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары, чаралары. Көтелгән соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау, Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары

Программаның максаты – шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдә булган закон таләпләренең һәм нормативларның Казан шәһәре территориясендә үтәлешен тәэмин итү.

Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1) капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү;

2) Казан шәһәре территориясендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм файдалану очракларын кисәтү буенча эш оештыру;

3) муниципаль программаны гамәлгә ашыруны оештыру ягыннан тәэмин итү.

Куелган бурычларны үтәү максатыннан түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру планлаштырыла:

беренче бурычны үтәү өчен:

1) Казан шәһәре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру барышында объектларны төзүгә, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирүне тәэмин итү, һәм реестрга кертелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү;

2) җирле әһәмияттәге һәйкәлләр реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздыруга рөхсәт бирү өлешендә җирле

(муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) Казан шәһәре территориясендә ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр уздыруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

Икенче бурычны үтәү өчен түбәндәге чараларны уздыру зарур:

1) гамәлдәге законнарны бозып, Казан шәһәре территориясендә җиткерелә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү очракларын кисәтү буенча үз вәкаләтләре кысаларында тиешле чаралар күрү;

2) гамәлдәге законнарны бозып, Казан шәһәре территориясендә җиткерелә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү турындагы мәгълүматны, материалларны, гамәлдәге законнар нигезендә чаралар күрү өчен, вәкаләтле органнарга юллау.

Өченче бурычны үтәү өчен түбәндәге чараларны уздыру зарур:

1) вәкаләтләр башкаруны ресурслар белән тәэмин итү.

Билгеләнгән программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне башкарырга мөмкинлек бирәчәк:

- Казан шәһәре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру барышында объектларны төзүгә, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирүне (озайтуны) тәэмин итәргә;

- җирле әһәмияттәге һәйкәлләр реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздыруга рөхсәт бирүне тәэмин итәргә;

- Казан шәһәре территориясендә ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр уздыруны раслый торган документ бирүне тәэмин итәргә;

- рөхсәт бирүне кире кагу турында карар бирүне тәэмин итәргә.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2025-2027 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына финанслана. Финанслауның гомуми күләме 92 392,2 мең сумны тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Казан шәһәре муниципаль бюджеты** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |
| 2025 | 30 081,1 | 30 081,1 | - |
| 2026 | 30 443,1 | 30 443,1 | - |
| 2027 | 31 868,1 | 31 868,1 | - |
| **БАР-ЛЫГЫ** | 92 392,3 | 92 392,3 | - |

Финанслау күләме фаразлау характерында бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Әлеге программа белән алдан каралмаган чыганаклардан өстәмә чаралар җәлеп ителгән очракта, Программаның заказ бирүчесе аңа тиешле үзгәрешләр кертә.

Башка финанслау чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның муниципаль заказ бирүчесе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе.

Программа чараларын үтәү муниципаль заказ бирүченең функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында административ регламент таләпләренең үтәлеше тәэмин ителә. Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында «бер тәрәзә» принцибы буенча электрон формада муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә этаплап күчү планлаштырыла.

Муниципаль программаларның муниципаль заказ бирүчеләре түбәндәгеләрне юллый:

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 числосына кадәр, программага 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат;

ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, муниципаль программаны әзерләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат.

Идарә Программаны гамәлгә ашыру барышын агымдагы контрольдә тотуны максатчан индикаторларны даими рәвештә мониторинглау юлы белән башкара.

## V. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән социаль-икътисади нәтиҗә төгәл күләмдә бәяләнә алмый, чөнки Программа һәрберсе билгеле бер уңай нәтиҗәгә ирешү юлы белән гамәлгә ашырыла торган чараларны үз эченә ала.

Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләүдә катнашу шәһәр төзелеше эшчәнлеген һәм җирдән файдалануны Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше законнары нигезендә оештырырга мөмкинлек бирәчәк, ә бу Казан шәһәренең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруның бер шарты булып тора. Территориаль планлаштыру документлары шәһәрне социаль-икътисади яктан үстерүнең төп юнәлешләрен гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге программаны гамәлгә ашыруның экологик нәтиҗәләре территорияләрдән шәһәр төзелеше буенча файдалануга экологик таләпләрне контрольдә тотудан гыйбарәт.

Нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлар үтәлешен анализлау юлы белән гамәлгә ашырылачак. Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә эшчәнлекләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләрен бозу очраклары ачыкланган юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең өлешен, шулай ук рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү фактлары санын киметү планлаштырыла.

«2025 – 2027 елларга Казан шәһәре
территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге
өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру»
муниципаль программасына
1 номерлы кушымта

**«2025 – 2027 елларга Казан шәһәре территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максаты, бурычлары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, программа чараларын финанслау**

| **Максат атамасы** | **Бурыч атамасы** | **Төп чаралар атамасы** | **Башкару-чылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлек-ләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | **Финанслау (чыганагын күрсәтеп), мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | **база елы** | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** |
| Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдә булган закон таләпләренең һәм норматив-ларның Казан шәһәре террито- | 1) капи-таль төзелеш объект-ларын төзүгә һәм файдала-нуга тапшыру-га рөхсәтләр бирү буенча муници- | - Казан шәһәре террито-риясендә урнашкан капиталь төзелеш объект-ларын төзегәндә, рекон-струкция-ләгәндә объектлар | Казан шәһәре Башкарма комитеты-ның Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе | 2025-2027 еллар | Законнар белән билгеләнгән вакыт эчендә бирелгән, объектларны төзүгә, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр, шулай ук Казан шәһәре территория-сендә ана (гаилә) капиталы | 100% | 100% | 100% | 100% | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| риясендә үтәлешен тәэмин итү | паль хезмәтләр күрсәтү | төзүгә, аларны файдала-нуга тапшыру-га рөхсәтләр бирүне тәэмин итү һәм реестрга кертелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү; | | | акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган шәхси торак төзелеше объектын төзү (реконструк-цияләү) буенча төп эшләр уздыруны раслый торган документлар өлеше | | | | | | | |
| | | - җирле әһәмият-тәге һәйкәлләр реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр уздыруга рөхсәт | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | бирү<br>өлешендә<br>җирле<br>(муници-<br>паль)<br>әһәмият-<br>тәге<br>мәдәни<br>мирас<br>объект-<br>ларын<br>саклауны<br>оештыру<br>һәм<br>гамәлгә<br>ашыру;<br>- Казан<br>шәһәре<br>террито-<br>риясендә<br>ана<br>(гаилә)<br>капиталы<br>акчаларын<br>җәлеп<br>итеп<br>гамәлгә<br>ашырыла<br>торган<br>шәхси<br>торак<br>төзелеше<br>объектын<br>төзү<br>(рекон-<br>струкция- | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ләү) буенча төп эшләр башкарылуны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү | | | | | | | | | | |
| | 2) Казан шәһәре территориясендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү очракларын кисәтү буенча эш оештыру | - гамәлдәге законнарны бозып, Казан шәһәре территориясендә җиткерелә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү очракларын | Казан шәһәре Башкарма комитетының Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе | 2025-2027 еллар | Казан шәһәре территориясендә җиткерелә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәтсез төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү буенча ачыкланган очраклар һәм гамәлдәге законнар кысаларында күрелгән | 100% | 100% | 100% | 100% | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кисәтү буенча үз вәкаләт-ләре кысалар-ында тиешле чаралар күрү;<br>- гамәл-дәге законнар-ны бозып, Казан шәһәре террито-риясендә җиткерелә торган капиталь төзелеш объект-ларын рөхсәтсез төзү, рекон-струкция-ләү һәм эксплу-атацияләү турында-гы мәгълү-матны, материал-ларны, | | | чаралар нисбәте | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | гамәлдәге законнар нигезендә чаралар күрү өчен, вәкаләтле органнар-га юллау | | | | | | | | | | |
| | 3) муни-ципаль програм-маны гамәлгә ашыруны оештыру ягыннан тәэмин итү | - вәкаләт-ләр башкару-ны ресурслар белән тәэмин итү | Казан шәһәре Башкарма комитеты-ның Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе | 2025-2027 еллар | Билгеләнгән вакыт аралыгында башкарылган йөкләмәләр өлеше | 100% | 100% | 100% | 100% | 29 073,7 | 30 443,1 | 31 868,1 |
| **Программа буенча барысы 92 392,3 мең сум** | | | | | | | | | | **30 081,1** | **30 443,1** | **31 868,1** |

«2025 – 2027 елларга Казан шәһәре
территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге
өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру»
муниципаль программасына
2 номерлы кушымта
(Форма)

## 20__ елның ________________ муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында хисап

| **№ т/б** | **Ярдәмче программа (бүлек, чара) атамасы** | **Финанслау чыганагы** | **Программаны раслау турындагы норматив хокукый акттан хисап елына планлаштырылган финанслау күләме, мең сумнарда** | **Программа буенча хисап чорына бүлеп бирелгән (лимит), мең сумнарда** | **Финанслау проценты** | **Ел башыннан фактта тотылган акча (башкаручы счетыннан күчерелгән), мең сумнарда** | **Индикатор атамасы, үлчәү берәмлеге** | **Индикатор күрсәткечләре** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | **узган ел** | | **агымдагы ел** | | | **киләсе елга план** |
| | | | | | | | | **план** | **факт** | **план** | **факт** | **башкару проценты** | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| Программа буенча барлыгы | | Барлыгы | | | | | | | | | | | |
| | | Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | | Казан шәһәре бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | | | | | | |